**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**Сарман авыл жирлеге**
**423350 Сарман авылы, Ленин ур.,52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: sar.sar@tatar.ru**
ИНН/КПП 1636005461/163601001

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово, ул.Ленина, 52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: sar.sar@tatar.ru**
ИНН/КПП 1636005461/163601001

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 14 18 сентября 2017 года

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль районда депутатлар белән очрашу үткәрү урыны һәм махсус бирелгән урыннарны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Сарман авыл Советы карары:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә депутатлар белән очрашулар үткәрү өчен махсус бирелгән урыннар һәм урыннар исемлеген билгеләргә (1 нче кушымта).

2. Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү тәртибе турында нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru махсус мәгълүмат стендларында һәм Сарман муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Сарман авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Н.И. Сахуриев